

ISSN 0868-4545

Салават күпере





Акбуз аттай томырылып,
Кил, Яңа ел, кил безгә —
Балачак дигән күңелле
Кадерле илебезгә!








Матурлык кабатланамы?

Бу сорауга «Юк!» дип җавап бирергә ашыкма, дускай.
Син үзең бик тә яраткан китапларны әледән-әле кулыңа аласың, укыйсың,
инде ничәнче мәртәбә сокланасың, уйланасың...
Матурлыкның кабатлануы түгелмени бу?!
Исеңә төшер әле: күңелеңә хуш килгән әкияти яисә мажаралы
кинофильмнарны кабат-кабат карарга тырышасың
(телевизордан күрсәтсеннәр генә!), шулай бит?!
Бу да Матурлыкның кабатлануы ләбаса!
Менә без дә «Салават күпере»нең моңарчы дөнья күргән саннарын янә
бер кат күздән кичереп чыктык та Матурлыкны үзебезчә кабатларга
булдык. Әүвәлге саннарда басылган матур-матур шигырьләрнең, әкиятләрнең
вә хикәятләрнең, рәсемнәрнең кайберләрен бергә туплап, ошбу журнал
битләрендә янә бастырыйк әле, дидек.
Әйдә, кабатлансын Матурлык! Ул карашларыбызга сеңсен,
күңелләребезгә иңсен, хәтерләребезгә сарылсын...



© "Салават күпере", 1998 ел

Шамил ФӘРХЕТДИН

Яңа ел бүләге



Әүвәл заманда дөньядагы барлык кош-кортлар һәм киек җанварлар Яңа ел бәйрәмен матур итеп, күмәк үткәрә белмәгәннәр. Һәр кош, һәр җанвар Яңа елны аерым-аерым каршылаган. Әлбәттә, аларның берсенә дә күңелле булмаган. Бергәләшеп бәйрәм итеп булуын башларына да китермәгәннәр алар. «Көчле көчсезне рәнҗетер»,— дип уйлаганнар.

Көннәрдән бер көнне Арыслан патша урманда «Салават күпере» дип аталган гаҗәеп матур журналга тап булган. Әтисе белән урманга Яңа ел чыршысына дип килгән бер малайдан төшеп калган икән журнал. Менә шул «Салават күпере» журналын алып укуы булган — Арыслан патша шаккаткан. Кешеләр Яңа ел бәйрәмен күмәкләп, җырлап-биеп, күңелле итеп уздыралар икән! Арыслан көнләшсә дә көнләшкән, көнләшмәсә дә көнләшкән.

Шуннан соң патша үзе дә Яңа ел бәйрәмен «Салават күпере»ндә сурәтләнгәнчә итеп каршыларга дигән фәрман чыгарган. Башта җанварлар бәйрәмгә шикләнеп кенә җыелсалар да, бергә-бергә күңелле һәм кызык икәнен күргәч, бик сөенгәннәр. Арысланга һәм «Салават күпере»нә зур рәхмәтләрен белдергәннәр. Арыслан исә, бу сөенечнең сәбәпчесе буларак, үзе дә бик шатланган. Хәтта урмандагы җан ияләренең барчасына «Салават күпере» журналын яздырткан. Бу аның үз патшалыгында гомер итүчеләргә Яңа ел бүләге булган. Әле дә булса ул патшалыкта мондый күркәм сүз яшәп килә икән: «Яңа елга иң кадерле бүләк — ул **«Салават күпере»**.

Рәссам Светлана ФАТТАХОВА



Сак-Сок

Татар халык бәете*

Мәдрәсәләрдә пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Әнкәй орышты тимер ук өчен,
Әнкәй орышты бигрәк юк өчен.

Җимнәр ташыйдыр кошлар басудан,
Әнкәй каргады безне ачудан.

Самовар куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды.

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.

Су буйларында бик күп йөрдек без,
Сак-Сок булгачтын, дөнья гиздек без.

Чыктык басуга, урак урырга,
Ходай язгандыр шулай булырга.

Су буйларында бала үрдәкләр,
Искә төшкәндә өзелә үзәкләр.



Урыныбыз урман, икебез туган,
Кавышу юк безгә, әнкәй каргаган.

Кояш чыкканда кан тула күзгә,
Кыямәт көнсез кавышу юк безгә.

Әнкәй елыйдыр, «ник каргадым» дип,
Сак-Сок йөридер, харап булдык, дип.


Кара карлыгач, сары сандугач,
Әнкәй елама, үзең каргагач.


Бик күп еласаң, китапка кара,
Безне сагынсаң, Сак-Сокка кара.

Китап укырсың, гыйбрәт алырсың,
Кошлар үткәндә карап калырсың.

Мәдрәсә-мәсҗед, пыяла ишек,
Сак белән Сокның бәетен ишет.

Идел буенда диңгез камышы,
Кара урманда Сак-Сок тавышы.





Җәй көннәрендә сайрый сандугач,
Әнкәй, елама, үзең каргагач.

Якты дөньяны күрми калабыз,
Карганды безне газиз анабыз.

Әткәй калдыргач, өйдә калдык без,
Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без.

Йокыга киткәч, бер төш күрдек без,
Җәй көннәрендә ялгыз йөрдек без,

Алты яшьләрдә бергә йөрдек без,
Җиде яшьләрдә Сак-Сок булдык без.

Әткәмез калды безнең мәчеттә,
Без тилмерәбез икебез читтә.

Әнкәй, кер юдың суның буенда,
Сак-Сок булыр дип юктыр уеңда.

Әнкәй каргады, әткәй, белдеңме?
Турыңнан очтык, әткәй, күрдеңме?


Кыскартып бирелде.

Рәссам Шамил НАСЫЙРОВ



Катя Бульчанова, 8 яшь.





Альбина Хәйруллина, 8 яшь.



Катя Гришина, 8 яшь.

Бу сәхифәдәге матур рәсемнәрне Казанның 140 нчы мәктәп-гимназия укучылары ясады. Аларның остазы - Наталья Александрова Орлова.



Сирай суы

(Тизәйткеч)

Сирайның суынмаган суына Сөббух суын салсаң, Сирайның суынмаган суы сиксән сигез секундта суына.

Булган, ди, бер кеше

Борын-борын заманда бер кеше булган,
Яланаякка балта кигән, ди.
Билбавына өч чаңгы кыстырган,
Урманга барган да юкә янында
Бау каезларга тотынган.
Анда бар икән, ди, өч үрдәк,
Ул үрдәкләр күлләрдә йөзеп йөргән,
Бу кеше аны күргән.
Өч таяк кисеп алып аткан,
Берсе барып җитмәгән,
Берсе үтеп киткән,
Берсе үрдәкләргә тигән, ди.
Үрдәкләр бик каты курыккан:
Берсе алды белән,
Берсе аркасы белән очкан,
Берсе арты белән күлгә чумган.
Күл очып киткән дә
Агач башына кунган, ди.

Табышмак әйтәм — тап

Җәй буе ял итәләр,
Кыш тәпиләп китәләр.

/Чаңгылар/

Җыйдык күп җиләк

(Такмаза)

Борын-борын заманда,
Әти дә тумаганда,
Киттек урманга,
Җиләк җыярга.
Гыйнуар ае иде,
Җыйдык күп җиләк —
Булды бер чиләк.
Алып кайтырга
Җиктек бер ишәк.




Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Аучы кәҗәләр

(Такмак)

Иртән торып тышка чыксам,
Сыерлар кар көриләр.
Ә кәҗәләр, мылтык тотып,
Куян атып йөриләр...



Рәссам Фәрит ЯКУПОВ

Рәссам абыегыз бу рәсемдә нинди ялгышлар җибәргән? Шуларны табыгыз әле.

Әкиятханә

Рөстәм Мингалим,
шагыйрь

Яшел күзле әнием

Мин хәзер зур.

Кайчандыр кечкенә чагым булган.

Көчкә-көчкә басып, бер урында гына басып тора белгән курчак шикелле булганмын.

Кайвакыт шундый итеп егылганмын... Кат-кат исемемне әйтеп тә, уенчыклар күрсәтеп тә, кулында тирбәтеп тә әнкәй мине юата алмаган. Авызымны йомарга онытып, тавышым белән бөтен өйне тутырып елаганмын... Ул чагында минем тавышым да, авызым да үземнән зур булган. Әнкәй шулай сөйләде... Әнкәм мине бик яраткан. Сөте белән сыйлаган. Аннан бишеккә салып тирбәткән. Йоклаткан. Ул чагымны мин хәтерләмим.

Үзем тиз үскәнмен. Аның саен тизрәк үсәргә, тизрәк йөреп китәргә тырышканмын. Тырыша торгач, бишектән дә егылып төшкәнмен.

Монысын да хәтерләмим.

Хәтерлим шуны: җәй, җылы, кояшлы көн иде. Су буенда төркем-төркем ак казлар йөри. Таллар яшел. Таулар яшел. Ярлар яшел. Безнең бакча башындагы елганың сай, төбе ташлы җирендә су тырпылдап ага. Әнкәй белән җитәкләшеп елганың аръягына — әрәмәгә чыгабыз. Су уртасына җиткәч, ни өчендер әнкәй миңа иелеп карады. Шулвакыт мин аның зур күзләрен күрдем... Күзләре яшел икән, яшел талларга, ярларга, тауларга охшаган. Аның күзләре — яшел җәйнең яшел күзләре шикелле.

Безнең авылдагы әниләрнең иң матуры — минем әнкәй. Бу уемны дусларым Нәҗип белән Наилгә дә әйттем. «Минем әни матуррак!» — диде Наил. Нәҗип тә бәхәсләште. «Минем әни матуррак!» — ди.

Бәхәсләшә торгач, ул көнне без сугыша яздык. Ярый шунда безне эзләп су буена әниләребез килде. Барыбер, аларның иң матуры минем әнкәй иде. Минем әнкәй, яшел күзле әнкәем... Ул чакта мин шуны да күрдем: Нәҗипнең әнисе зәңгәр күзле, Наилнең әнисе кара күзле икән...


Мин хәзер зур. Кайчандыр кечкенә булганмын. Мин сабый чагымны сагынып авылыма кайтам. Безнең бакча башыннан аккан елгачык тагын да саеккан...

Мин хәзер зур. Бәләкәй чагымда минем әткәй генә юк иде. Хәзер әнкәем дә юк. Дусларым Наил белән Нәҗип тә юк.

Ә җәйләр миңа һаман әнкәемнең яшел күзләре белән карыйлар...



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Газинур Морат

Хәрәкәттә — бәрәкәт

Әбекәем намаз укый —
Мин читтән карап торам;
Аның һәр ым-хәрәкәтен
Искәреп, барлап торам.

Өч тә түгел, дүрт тә түгел —
Нәкъ биш мәртәбә көнгә
Әбекәем намаз укый
Мин аңламаган телдә.

Иелә дә турая ул,
Турая да иелә —
Шуңа, ахры, әбекәйнең
Сызламыйдыр биле дә.

Хәрәкәттә — бәрәкәт, ди,—
Минем әби тапкыр ул,
Көн дә физзарядка ясый —
Шуңа көләч, матур ул.

Хәкимҗан Халикъ

Беләсеңме?

Үзе яхшының
Эше дә яхшы,
Үзе яхшыга
Кеше дә яхшы.



Коенса да...

Кырда бигрәк
Каралдым, дип,
Агарыйм, дип,
Кара карга
Су коенып
Алган, имеш,
Ләкин шул ук
Карга булып,
Кара булып
Калган, имеш.

Ара-тирә

Кайчагында Нургали дә
Тырыштыргалаштыргалый:
Ара-тирә колагын да
Юыштыргалаштыргалый.



Рәссам Шамил НАСЫЙРОВ

Кем нәрсә ярата?

Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч һәм Кәҗә яшәгәннәр. Кич белән алар ишек төбенә җыелалар да үзләренең эшләре турында сөйләшәләр икән. Сөйләшәләр дә бәхәсләшеп тә китәләр икән. «Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк?» — дип бәхәсләшәләр икән.

— Иң тәмле сый — сөт, — ди Песи. Сөттән соң бер тычкан да тотып кабып җибәрсәң, бигрәк тә шәп була инде! Тик тычканны тотуы кыен.

— Сөт нәрсә? Ул бит сыек, тамак туйдырмый. Ә менә ярма бөртекләрен, солы орлыгын тук-тук итеп чүпләсәң, менә шунда тамак тук-тук-тук була! — ди Әтәч.





— Юк-юк! — дип сүзгә кушыла Акбай. — Бөртек чүпләп кенә туеп бул-бул-булмый. Менә сөяк кимерсәң, чынлап та әйбәт була, шунда ук тук буласың. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.

— Нәрсә сөйлисең син, — дип каршы килә Кәҗә. — Менә кәбестә-ә-ә булса икән. Иң тәмле азык — кәбестә-ә-ә, — ди ул.

Алар бәхәсләшәләр икән — әле һаман килешә алганнары юк, ди.





Рәссам АЛЛА АЙСИНА

«Кыш бабай, зинһар,



Журналыбызның 10 нчы санында (1998 ел) без укучыларыбызга болай дип дәшкән идек: «Кыш бабайга әйтәсе нинди дә булса теләгең, хыялың, сүзләр сүзең бардыр дип ышанабыз. Күңелеңдә генә калмасын, шуларны ак кәгазьгә төшер дә — «Салават күпере»нә юлла...»

Журналханә укучылардан бик күп хатлар алды. Без, Кыш бабай белән бергәләп, ул хатларның барчасы белән танышып чыктык. Игътибарыгызга аларның кайберләрен тәкъдим итәбез һәм бер уңайдан Кыш бабайдан сезнең хыял-теләкләрегезне үтәвен үтенеп калабыз.

Кыш бабай!

Мин Яңа елны бик яратам, ләкин бәйрәмдә киярга күлмәгем юк. Аны алырлык акчабыз юк. Быел өй салырга җыенабыз. Әнием эшсез. Әтигә дә акча аз тия. Әбиләргә дүртенче ай инде пенсия бирмиләр. Кыш бабай, зинһар, хәлемә керегез инде. Бөтен өмет Сездә, Сезгә ышанып торам. Бүтән бернәрсә дә сорамыйм.

Гүзәл Нургалиева, 12 яшь. Балтач, Бурнак.

Кыш бабай!

Минем бер хыялым бар. «Салават күпере»ндә «Танышу әлемтәсе» дигән сәхифә булсын иде. Ул сәхифәгә дуслар эзләүче малайлар һәм кызлар хатлар язарлар иде. Шушы хыялым үтәлсә, мин бик шат булачакмын. Сезгә ышанып калам. Үзем яхшы укыйм. Бу чиректә бер генә дүртлем чыкты, калганнары - гел бишле. Шул уңайдан кечкенә бер мәзәк хәл: беркөнне капкадан чыкканда бер бабай миңа:

- Кара, кызым, бер «5»лең капкага кысылып калды бит! - диде.

Сау булыгыз!

Алия Сахаватова, 11 яшь. Әлмәт, Сөләй.

Кыш бабай!

Без сине сагынып көтәбез. Бәйрәмгә җырлар, шаян уеннар әзерләдек инде. Безгә бүләкләр алып кил, яме. Миңа укучылар сумкасы алып килсәң, бик шат булыр идем. Сиңа хат яза һәм сине көтә - дүртенче сыйныфта укучы кызың Гөлшат.

Гөлшат Булатова, 10 яшь. Башкортостан, Миякә.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

«...хәлемә керегез...»

Кыш бабакай! Исәнме!

Синең килүең турында «Салават күпере»ннән әнием укыгач, мин бик шатландым. Чәбәкәйли-чәбәкәйли биеп тә алдым.

Мин Башкортостанның Чакмагыш авылында яшим. Әле миңа 5 яшь. «Кояшкай» балалар бакчасына йөрим. Без инде Яңа елга җырлар, биюләр өйрәнә башладык. Тизрәк килеп кенә җит. Бездә кыш җитте инде.

Синең, Кыш бабай, капчыгың бик зур була. Анда хәтсез күчтәнәчләр сыя инде. «Салават күпере»н дә алып кил, яме, Кыш бабай. Мин аны бик-бик яратам.

Кыш бабай, сине түземсезлек белән көтеп калам. Үзеңә ак юллар, ак бураннар, ак бәхетләр генә юлдаш булсын безгә килгәндә.

Кечкенә Айдар исеменнән хатны әнисе язды.

Айдар Мусин, 5 яшь.

Кыш бабай!

Мин рәсем ясарга бик яратам. Үскәч рәссам булырга телим. Берәр рәсемем «Салават күпере»ндә басылса, минем өчен бик зур сөенеч булыр иде.

Гөлләр Гыйльфанова, 12 яшь.
Кама Тамагы, Кыртапа.

Кыш бабай!

Минем теләкләрем, хыялларым, сөйләр сүзләрем бик күп. Мин теләгемнең берсен генә әйтәм. Миңа яңа баян кирәк иде. Зинһар, теләгемне үтәгез инде.

Динар Хәйретдинов, 11 яшь.
Питрәч, Ленино-Кокушкино.

Исәнме, Кыш бабай! Хәлләрең ничек? Безнең Бикмураз авылына да киләсеңме? Мин өченче сыйныфта укыйм. Апам бар. Наилә исемле. Икебез дә яхшы билгеләргә генә укыйбыз. Мин математикадан мисаллар чишәргә яратам. Калькулятор бүләк итә алмассыңмы икән? Апама матур, йомшак ак куян алып килә алсаң, әйбәт булыр иде. Кыш бабай, сине түземсезләнеп көтеп калабыз.

Наил Шәфигуллин, 9 яшь.
Буа, Бикмураз.

Салават күпере

1(107) - 1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары - җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Валерий ЛУГВИНЕВ рәсемнәре

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 30.12.98 ел.
Басарга кул куелды 30.12.98 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 17000 данә. Заказ Я-618.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бөясе килешү буенча
Индекс 73953

